ЯРДӘМ КУЛЫ

Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләре башлыклары безгә нигә рәхмәтле?

> 2

ИГЪТИБАР КИРӘК

Инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарга пособие күләме арта

> 2

МИНИСТР ӘЙТТЕ

Мәгариф тармагындагы иң мөһим алты темага ачыклык керттеләр

> 3

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ИЛСӨЯ

21 ел сәхнә тоткан җырчы быелниләр белән шаккатырды?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 188 (29155) | Чәршәмбе | 20 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЯҢА ИСКЕНЕ ОНЫТТЫРМЫЙ

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР СЪЕЗДЫ НИНДИ ПРОБЛЕМАЛАРНЫ АЧТЫ?

Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре арасында 30 яшькә кадәрге кешеләр нибары 10 процентны гына алып тора. Ә 55 яшь һәм аннан өлкәнрәкләр, киресенчә, арта.«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясенең XVIII съездында проблемаларның искеләре дә, яңалары да күтәрелде. Уңышлар белән бергә яңа бурычлар да куелды.

Яшьләрнең авыллардан китү мәсьәләсе бу юлы да игътибардан читтә кала алмады. Рәхәтләнеп яшәр өчен шәһәрнекеннән ким булмаган шартлар да бар югыйсә, диде ассоциация рәисе Әгъзам Гобәйдуллин.

– Районнарда торак салу елдан-ел арта: ун ел эчендә бу күрсәткеч 30 процентка артты, – диде ул. – Ун ел эчендә республикада 27 млн кв. метр торак төзелгән, шуларның 14 млн кв. метры – районнарда. Авыл кешесе район үзәгендә йорт салса да, ул мегаполиска китмичә, тормышын кече ватаны белән бәйли дигән сүз. Бу күзлектән караганда, һәр районда да халыкны җыярдай, таяну пункты булырдай авыллар булырга тиеш. Ләкин иң мөһиме – һәр авыл җирлеге буенча җитештерү көчләрен урнаштыруның төгәл схемасын билгеләү кирәк. Алар эре предприятиеләрнең филиаллары, эшкәртү һәм азык-төлек сәнәгате булырга мөмкин. Комплекслы программа кирәк, – диде Әгъзам Гобәйдуллин.

Җитәкче кооперативларга да игътибарны көчәйтергә кушты.

– Ел саен күпчелек районнарда кооперативлар саны арта, моңа уңышлы мисаллар да күп. Шуның белән беррәттән, бу төр форманы үстерер өчен мөмкинлекләр дә шактый. Тик әлегә 10 мең кеше генә кооператив әгъзасы булып тора. Бүген аларны үстерер өчен субсидияләр, грантларны файдалану мөмкинлеге бар. Муниципалитет җитәкчеләреннән аларны үстерер өчен зуррак игътибар бирүләрен сорыйбыз, – диде Әгъзам Гобәйдуллин.

Саннар

✓ Бүген Татарстанда **956** муниципаль берәмлек, **7** меңнән артык депутат, **6700** муниципаль хезмәткәр бар. **872** авыл җирлеге эшли.
✓ Республикада соңгы **10** елда территориаль иҗтимагый үзидарәләр саны **4** тапкыр артып, **463**кә җитте. Анда **1** млн **700** мең кеше яши.
✓ **2012** елдан бирле халык үз территорияләре үсеше өчен **2,4** млрд сум акча керткән. Республика бюджетыннан **9** млрд сумнан артык акча бүлеп бирелгән.

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев «Теләкләр чыршысы» акциясендә катнашты. Рөстәм Миңнеханов дүрт баланың хыялын тормышка ашырачак. Әйтик, Байлар Сабасында яшәүче малай телескоп сораган, тагын бер бала акыллы колонка турында хыяллана. Зәйдән бер сабый «Ак барс» хоккей командасы белән очрашырга тели. Казанда яшәүче баланың хыялы – Кавказ тауларын күрү.

Елдан елга күчеп килә торган тагын бер проблема: халыкны су белән тәэмин итү. Соңгы елларда бу четерекле мәсьәләне хәл итәргә ярдәм итүче өстәмә чаралар бүлеп бирелсә дә, авырлыклар күп.

– Быелгы коры килгән җәй әлеге проблеманы тагын да кискенләштерде, кайбер территорияләрдә скважиналардан алына торган суның җитмәве ачыкланды, күп су яшелчәләргә сибү өчен тотыла. Соңгы елларда республика хөкүмәте су белән тәэмин итү системасын үстерү буенча өстәмә чаралар кабул итте. Барлык программалар (федераль һәм республика, үзара салым, грант) буенча су белән тәэмин итү системасын төзү, төзекләндерү һәм яңарту өчен 3,5 млрд сум акча бүлеп бирелде. Шуның белән беррәттән, статистика күрсәткечләре буенча суүткәргеч системаның 60 проценты алыштыруны таләп итә, – диде Әгъзам Гобәйдуллин һәм бу эшләр өчен федераль бюджеттан күбрәк акча бүлеп бирү кирәклегенә басым ясады.

Әлеге проблеманы үз чыгышында Түбән Кама мэры Рамил Муллин да күтәрде. Аның сүзләренчә, коммуналь инфраструктураларның 70 проценты тузган. Аларны яңарту өчен җирле һәм республика бюджеты гына җитми, федераль ярдәмнең булуы кирәклеген ассызыклады ул. Моннан тыш, Рамил Муллин шәһәрдә җәмәгать транспортын яңарту, аның эшен көйләү буенча да авырлыклар булуын әйтте.

– Авыллардагы юлларны карап тотуга тәгаенләнгән суммалар 2015 елдан бирле үзгәрмәде. Халыкның ихтыяҗы елдан-ел арта, ләкин без аларны канәгатьләндерә алмыйбыз. Шуңа күрә әлеге сумманы индексацияләү кирәк, – диде Рамил Муллин.

Ахыры 2 нче биттә >

4 триллионга җитәчәк

Ел йомгаклары буенча төбәкнең тулай продукты акчага салып исәпләгәндә 4 триллион сумга җитәчәк. Республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, узган елдагыга караганда 2,8 процентка зуррак сан бу.

Тәгаенләп әйтсәк, 4,5 триллион сумлык сәнәгать продукциясе, 280 миллиард сумлык авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерелгән. Ваклап сату өлкәсендә товар әйләнеше – 10 процентка, инвестицияләр 8 процентка арткан.

Рәис сүзләренә караганда, икътисадның төп тармакларында эш әйбәт бара. Шул ук вакытта федераль үзәкнең дә ярдәме зур.

Яшәү минимумы арта

Республикада 2024 елга яшәү минимумы билгеләнгән. Ул 169 сумга артып, җан башына 13135 сумга җиткән. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән тиешле карарга кул куйган.

Исегезгә төшерәбез: яшәү минимумы – кешегә иң мөһим ихтыяҗларын тәэмин итү (иң кирәкле азык-төлек, кием-салым сатып алу, «коммуналка»га түләү) өчен кирәкле минималь керем. Хезмәт хакы аннан ким була алмый. Яшәү минимумы эшләүчеләр, пенсионерлар, балалар өчен аерым билгеләнә. Киләсе елда ул эшләүчеләр өчен – 14317 сум (14113 сум булган), пенсионерлар өчен – 11296 сум (11151 сум), балалар өчен 12741 сум (11852 сум) тәшкил итәчәк.

Әйтергә кирәк, яшәү минимумы күләме быел сентябрь аенда кабул ителгән карарга үзгәрешләр кертелү нәтиҗәсендә арткан. Әлеге карар буенча 2024 елга ул 12966 сум тәшкил итәргә тиеш булган. Гомумән алганда, киләсе елга яшәү минимумы 2023 елга билгеләнгән күрсәткечкә караганда 916 сумга артачак.

Телефонны тыйдылар

Президент Владимир Путин мәктәптә балаларга дәресләр вакытында телефоннан файдалануны тыйган законга кул куйган. Документ хокукый мәгълүматлар рәсми порталына урнаштырылган.

Закон нигезендә, гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда гына кесә телефонына үрелергә рөхсәт итәчәкләр. Укучылар һәм укытучыларның гомеренә, сәламәтлегенә куркыныч янаган очракларда гына телефонны кулга алырга мөмкин булачак дигән сүз бу.

Документны октябрь аенда Дәүләт Думасына Мәгърифәт комитеты рәисе Ольга Казакова җитәкчелегендә бер төркем депутатлар һәм сенаторлар керткән. Башта укучыларга белем алу максатында телефоннан файдаланырга рөхсәт итү күздә тотылган булган. Әмма соңыннан бу нигезләмә юкка чыгарылган. 6 декабрьдә Дума закон проектын соңгы укылышта кабул иткән. Бер атнадан соң аны Федерация Советы хуплаган.

Тиз ачыклый башлаганнар

Соңгы атнада республикада 28904 кешенең грипп һәм ОРВИ йоктыруы теркәлгән. Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе мәгълүматларына караганда, 2022 елның 50 нче атнасы (11–17 декабрь аралыгы) белән чагыштырганда, хәзер чирләүчеләр саны 30 процентка кимрәк. Шул ук вакытта соңгы җиде көндә 1913 кешенең грипп йоктыруы ачыкланган. Узган елның шушы ук чорындагыга (413 очрак) караганда 4,6 тапкыр зуррак сан бу. Республикада яшәүчеләр А гриппын күбрәк йоктыра.

Белгечләр әйтүенчә, грипп өлеше арту ОРВИ билгеләренә ия булган сырхауларга экспресс-тестларны күбрәк үткәрә башлауга бәйле.Тест грипп вирусын башкаларыннан аеру мөмкинлеге бирә икән.

Табиблар грипп һәм ОРВИ очраклары арткан бер мәлдә җәмәгать урыннарында медицина битлеген киярга, кулларны ешрак юарга, антисептиклар кулланырга, җылырак киенергә, үтәли җилдән сакланырга, ә инде чир билгеләре күренүгә, өйдә калып, табибка күренергә киңәш итә.

Яшәеш

Итек ачкан ишекләр

2024 ЕЛДА ОНЛАЙН СӘҮДӘ ЮНӘЛЕШЕН НИ КӨТӘ?

Татарстанда онлайн сәүдә үсеше... итектән башланган. Ник икәнен соңрак белерсез. Гомумән, электрон сәүдәнең әйтеп бетергесез әһәмияте һәм файдасы барлыгын барысы да таныды бугай инде. Әмма чишәсе мәсьәләләр дә юк түгел. Казанда узган «Мой бизнес. E-COM» форумында шуларга игътибар иттеләр.

Аз гына статистика. Соңгы өч ел эчендә Татарстанда селлерлар саны (маркетплейсларда үз товарларын сатучыларны шулай атыйлар. – **Авт.**) 174 тапкыр арткан. Хәзер андыйлар саны – 55919 кеше. Татарстанда теркәлгән юридик затларның 12 проценты бу. Татарстанның электрон сәүдә өлкәсендәге товар әйләнеше 46 миллиард сумга кадәр артты, шуның нәтиҗәсендә республика Россиянең бу юнәлештә иң уңышлы 10 төбәге арасына керә. Ел башыннан Татарстанда гына да онлайн сәүдә мәйданчыкларында 92 млрд (!) сумлык сатып алулар теркәлгән.

Тынычланырга ярамый

Ә барысы да итектән башлана. Татарстанның эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Рәис ярдәмчесе Фәрит Габделганиев сүзләренчә, өч ел элек Кукмара эшмәкәре республика Рәисе Рөстәм Миңнехановка үз продукциямне маркетплейсларга чыгара алмыйм дип зарланган. Югыйсә эшмәкәр бөтен дөнья буенча сату итә икән инде. Җитештергән продукциясе АКШ, Мальта, Гарәп Әмирлекләренә кадәр барып җиткән. Тик җирле маркетплейсларга юл ябык.

– Бу мөрәҗәгатьтән соң электрон сәүдәгә бәйле программа барлыкка килде, өч ел эчендә аның нигезендә яңа сатучыларны җәлеп итү буенча эш башкарыла, – дип сөйләде бизнес-омбудсмен.

Аның әйтүенчә, Татарстан – төбәктә интернет-сәүдәне үстерү буенча алдынгылар арасында.

– Әмма тынычланырга ярамый. Безгә әлеге тармакның кая таба барганын, киләсе елда нәрсә көткәнен белергә кирәк, – дигән фикердә Фәрит Габделганиев.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Гөлшат НИГЪМӘТУЛЛИНА, Татарстан Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы:

Республикада өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрнең саны елдан-ел арта бару сөендерә. Бу – барлык туучы сабыйларның якынча 30–32 проценты. Күпбалалык вазгыяте республикада булдырылган социаль ярдәм чараларына һәм халкыбызның әхлакый нигезләренә бәйле.

(«Татар-информ»га биргән әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ҮЗМӘШГУЛЬЛӘР

«Трезвая Россия» иҗтимагый хәрәкәте Россиянең иң аек һәм эчкече төбәкләрен ачыклаган.

Иң «аек» төбәкләр	Иң «исерек» төбәкләр
>> Чечня	>> Курган өлкәсе
>> Дагыстан	>> Чукотка
>> Ингушетия	>> Бурятия



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЯҢӘ КОАЛИЦИЯ, ЯҢӘ СУГЫШ

Фәләстыйндагы канкоеш бөтен Якын Көнчыгыш конфликтына әверелү ихтималын югалтмады. Киресенчә, хәл кискенләшә һәм дөнья икътисадының төп кан тамырларыннан берсе булган сәүдә маршрутын куркыныч астына куя.

Йәмән гыйсъянчылары, Газзәгә теләктәшлек белдереп, Кызыл диңгез аша Израильгә таба һәм Израильдән баручы сәүдә корабларын туктатуга иреште. Аларның әмеренә буйсынмаучы кораблар я тотак итеп алынды, яисә ракета һәм беспилотник һөҗүмнәренә дучар булды. Нәтиҗәдә иң эре транспорт компанияләре CMA CGM, Maersk, Hapag-Lloyd һәм ZIM Сүәеш каналы, Кызыл диңгез һәм Аден култыгы аша йөк ташуны туктатуларын игълан итте. Азиядән Израильгә, Израильдән Азиягә товар йөртү кыйммәткә төшә башлады. Кыска маршрут аша бару хәвефле, иминиятләштерү компанияләре моның өчен бик зур акча сорый. Африка аша әйләнеп узу 5 мең километрга ераграк. Израильнең Эйлат портына сәүдә кораблары керүдән туктады, сиончылар көн саен миллионлаган доллар акча югалта. Әмма катастрофа бер аларга гына түгел, Сүәеш каналы аша үткән кораблардан акча җыю хисабына зур табыш алган Мисырга да яный. Мисырга керә торган табыш ике тапкыр кимеде. Илдә исә икътисадый-сәяси хәл бик киеренке: инфляция, девальвация бездәгедән дә көчле. Бәяләрнең күтәрелүе 2011 елгы революциянең кабатлануына китерергә мөмкин.

Йәмән гыйсъянчыларының ракеталар атып уйнавы төбәктәге башка илләргә дә суга. Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Согуд Гарәбстаны диңгез блокадасына риза түгел. Вазгыятьтән баштарак Британиянең диңгез корабларын иминиятләштерүче компанияләр файда күргән иде. Алар кесәсенә яуган табыш кискен артты.

Йәмәнлеләр, бер караганда, гадел шартлар куя үзе: Газзә блокадада булганда, Израиль дә блокадада булачак, Газзәгә гуманитар ярдәм кертелсә, без дә блокаданы туктатачакбыз, диләр. Әмма сугыш карчыгалары алар сүзенә колак салмый. АКШның оборона министры Ллойд Остин, гыйсъянчыларга каршы тору өчен, коалиция төзү турында игълан итте. Сишәмбе көнне Якын Көнчыгыш дәүләтләре һәм башка илләр виртуаль сөйләшүләр алып барачак (бу юллар сишәмбе иртәсендә языла). АКШ башка илләр белән берлектә Кызыл диңгездә «Чәчәк ату сакчысы» дигән хәрби операция башлаячагын әйтте инде. Моңа җавап итеп, йәмәнлеләр Якын Көнчыгыштагы нефть скважиналарын шартлатырга вәгъдә итә. Сугыш башлана калса, дөнья икътисадының һәлакәтле сценарие тормышка ашырылачак.

Россиядә

НЕФТЬ: ПОШЛИНА БЕТӘ, САЛЫМ АРТА

Финанс министрлыгы сайтында белгечләрне сагаерга мәҗбүр иткән белдерү пәйда булды: 2024 елның 1 гыйнварыннан нефтьнең экспорт пошлинасы бетерелә. Пошлина түләү бер нефтькә генә түгел, нефть продуктларына, бензинга, дизель ягулыгына һәм кокска да туктатыла. Экспорт пошлинасы юкка чыгарылгач, кара алтынны, эшкәртеп тормыйча, чит илләргә озату табышлырак була башлый.

Финанс министрлыгы казнага керә торган акча агымыннан баш тартмый, билгеле. Бер кулы белән пошлинаны бетерсә, икенче кулы белән файдалы казылмалар чыгаруга салымны арттыра. Министрлык белгечләре исәпләп эш итә торгандыр, бюджет оттырмыйдыр. Моңа берәү дә шикләнми. Шулай да салым маневры вәсвәсә уята: нефть чит базарларга агылып, эчке базарда ягулык дефициты пәйда булмасмы? Экспорт пошлинасының максаты бит казнага акча туплау түгел, товарны читкә озатуны кыенлаштырып, эчке базарны дефициттан коткару нияте иде. Бу уңайдан «Российская газета»га тармак белгече Вячеслав Мищенко: «…экспортные пошлины на нефть и нефтепродукты были эдаким естественным демпферным механизмом на нашем внутреннем рынке, сдерживающим рост цен. Сейчас, в период действия санкций, очень сложно анализировать последствия и просто посчитать, что будет с ценами, поскольку неясны до конца вводные данные», – ди. Аның фикеренчә, ягулыкка күпләп сату бәяләре үсәр, әмма ваклап сату бәясе инфляция күләменнән артмас. Ягулык салу станцияләрендәге бензин һәм солярка бәясен монополиягә каршы көрәш хезмәте игътибар белән күзәтеп торыр һәм кискен үзгәрешләргә юл куймас.

Экспорт пошлиналарының бетерелүе, мөгаен, Көнбатыш санкцияләре тәэсиреннәндер. 2022 елның декабреннән нефтьне диңгез аша сатуга, 2023 елның февраленнән нефть продуктларын сатуга эмбарго кертелде. Боларга өстәп нефтьнең баррелена – 60 долларлык, ачык төстәге нефть продуктларына – 100 долларлык, караңгы төстәгеләренә 45 долларлык чик бәяләр куелды. Нәтиҗәдә Россия нефте бик зур дисконт белән сатыла. Нефть экспортын кыенлаштыра торган андый тышкы басымга Хөкүмәт пошлиналарны бетереп җавап бирергә булган, күрәсең. Бу маневрның нәтиҗәләре нинди буласын әлегә өзеп бер белгеч тә әйтә алмый. 2024 елга санаулы көннәр калды. Ел башында базар үз сүзен әйтер.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

БЕР ЙОДРЫКТА

Татарстан ярдәме белән үзгәрдек. Казанга килгән Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләре башлыклары республикага рәхмәтен әнә шундый сүзләр аша җиткерде. Алар Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашып, киләчәктә башкарылачак эшләр хакында сөйләште. Сүз уңаеннан, кунаклар Муниципаль берәмлек советы съездында да катнашты.

tatarstan.ru

Кунакларны буш кул белән җибәрмәделәр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләре җитәкчеләренә автомобиль ачкычлары тапшырды. Моннан тыш хәзер ике шәһәр җитәкчеләре Татарстанның муниципаль берәмлекләре советы әгъзалары булып та торачак.

Татарстан ярдәм итеп торганга күрә, Лисичанскида инфраструктура торгызыла, су һәм электр энергиясен эшләтеп җибәрү юнәлешендә күп эш башкарыла. Лисичанск шәһәре мэры Эдуард Сахненко әйтүенчә, республика Россиянең яңа төбәгенә тыныч тормыш бүләк итте.

Ул Татарстанга, гуманитар йөк җибәреп торулары өчен, аерым рәхмәтен әйтте. Мәгълүм булганча, Татарстан бу шәһәргә барлыгы 2 мең тоннадан артык азык-төлек җибәргән.

– Без хәзер Татарстандагы шәһәр идарәсе тәҗрибәсен үзләштерергә җыенабыз, – дигән ул «Татар-информ» хәбәрчесенә. – Киләчәктә исә сәнәгать комплексын торгызуда ярдәм сорарга телибез. Кешеләргә эшләргә урын кирәк.

Рубежное шәһәренә дә тормыш кайта. Шәһәр администрациясе башлыгы Сергей Хортив әйтүенчә, Татарстан шефлыгында Рубежноеда барысы да үзгәргән.

– Башлангыч ремонт өчен кирәк-яракларыбыз булды. Кышка шулай әзерләндек, – ди ул. – Татарстан әле дә ярдәм итеп тора. Үз көнебезне үзебез күргәндә бик авыр иде. Су белән тәэмин итү, су чыгару мәсьәләләре хәл ителде. Моннан бик күп кеше газаплана иде. Татарстан ярдәме белән монысы да хәл ителде. Татарстанның ярдәмгә килүе безнең өчен сөенечле хәбәр булды. Киләчәккә дә өметләребез зурдан.

Киләчәк димәктән. Татарстан Рәисе белән очрашуда сүз мәктәпләрне һәм хастаханәләрне ремонтлау турында барды. Хәзер социаль учреждениеләрне җиһазлар белән тәэмин итү бурычы тора.

Моннан тыш Эдуард Сахненко һәм Сергей Хортив берничә социаль, спорт һәм мәдәни объектларны карады, Бәшир Рәмиев исемендәге IT паркка керде, ТКХ һәм җылылык бирү челтәре өлкәсендәге эш белән танышты.

Яңа искене оныттырмый

<Ахыры. Башы 1 нче биттә

Муниципалитетларда проблемалар гына түгел, уңышлар да бар анысы. Программалар, үзара салымнар, грантлар ярдәме белән юллар төзекләндерелә, зиратлар, су башнялары карала, зират коймалары яңартыла, балалар мәйданчыклары сафка баса. Әйтик, быел грантлар суммасы артып, 2 млн сумны тәшкил итте. Бу акчага 82 муниципалитет тракторлар сатып алды. Әлеге техника территорияләрне төзекләндерергә һәм юлларны үз техникалары белән тәртиптә тотарга мөмкинлек бирә.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов съездда катнашучыларга: «Сез гражданнар белән турыдан-туры эшлисез, алар белән көндәлек элемтәдә торасыз», – дип мөрәҗәгать итте.

– Эшегезнең нәтиҗәлелегенә, халык белән аралашуга бәйле рәвештә гражданнарның барлык дәрәҗәдәге хакимият органнарына мөнәсәбәте формалаша. Соңгы елларда тулаем илдә дә, республикабызда да, һәр шәһәрдә һәм районда гражданнарның тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән зур эш башкарылды, – диде ул.

Шул ук вакытта хәл итүне таләп итүче һәм халыкны борчыган мәсьәләләрнең дә күп калуына басым ясады.

– Тормыш һәр көн безнең алда яңа бурычлар куя. Барлык проблемаларны берьюлы хәл итеп булмый. Бу хакта халык белән сөйләшүләр алып барырга кирәк. Халыкка территорияләрне үстерүнең өстенлекле бурычлары, аларны гамәлгә ашыру буенча хакимият органнары алып барган эшләр, теге яки бу проблемалы мәсьәләләрне хәл итү вакыты һәм этаплары турында хәбәр ителергә тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Итек ачкан ишекләр

<Ахыры. Башы 1 нче биттә

Киләчәккә фараз

Татьяна БАКАЛЬЧУК, «Wildberries» маркетплейсына нигез салучы:
– Мин, ана һәм гади кулланучы буларак, онлайн сәүдәгә әле кермәгән әллә нәчә төрле товар атый алам. Мәсәлән, минем ике бәләкәй балам бар. Аларга ике яшь. Мин аларга ярарлык кием таба алмыйм. 1 яшькәчә балаларга әле нидер табарга була. Әмма яше арткан саен, сайлап алу мөмкинлеге азая, төрлелек юкка чыга. 7 яшьлек балама гомумән сәгатьләр буе үз кибетемдә товар карап утыра алам. Бу юнәлеш әлегә урып-җыелмаган кыр төсле. Эшмәкәрләр нәрсә тәкъдим итүләрен уйласын иде.

Сергей БЕЛЯКОВ, «Озон» идарәче директоры:
– Электрон сәүдә феноменының асылы шунда ки, ул бик тотрыклы. Хәтта бик көчле чикләүләр кысасында да без үсәргә сәләтле. Татарстан җитәкчелеге электрон сәүдәне көченнән килгәнчә үстерергә һәм аларга теләктәшлек күрсәтергә тырыша. Әгәр дә икътисадны алга сөрүче көч бар икән, аның үсешен тоткарлау ник кирәк?

Дмитрий РУСАКОВ, «Яндекс» вәкиле:
– Маркетплейсларда буш булган юнәлеш табу, чынлап та, җиңел түгел. Бер мисал китерәсе килә. Бездә шәхси гигиена кирәк-яраклары белән проблемалар бар икән. Без хатыным белән косметика кибетенә кергән идек. Ул миңа кулына алган һәр сабынны күрсәтеп, иснәтеп торды, «Моның белән кул юар идеңме?» – дип сорашты. Кешегә сабынның күбекләнүе генә түгел, хуш исле һәм матур булуы да мөһим. Шәхси гигиена кирәк-яраклары кешеләр маркетплейсларда кызыксынып караган товарлар исемлегендә икенче урында тора. Өченче урында – көнкүреш хуҗалык товарлары.

Линар ХӨСНУЛЛИН, «KazanExpress» генераль директоры:
– Алдагы ике ел электрон сәүдә тармагына яңа гына килеп кушылганнар өчен хәлиткеч булачак. Компанияләр иртәме-соңмы комиссия хакын күтәрәчәк (әйтик, сатудан комиссия), алар да үзләренә зыянга эшләүдән арачак. Әйтик, мисал өчен, «Amazon» сату мәйданчыгында комиссия күләме 50 процентны алып тора.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Татулыкка ирешү сере

Дәүләт Советында

Бала кечкенәдән үк тиешле тәрбия алмаса, үскәч, үз теләге белән сайлауга бармаячак. Дәүләт Советы Рәисе, «ТЯГ» Югары советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Татарстан – Яңа Гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәте Югары советы утырышында шундый фикер әйтте.

Халыклар дуслыгы йортында узган чарада, яшьләрнең рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезе буларак, ватанпәрвәрлек, гражданлык хисе һәм мәдәни тәңгәллекне булдыру мәсьәләләре каралды.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, бүген яшь буында ватанпәрвәрлек рухын, гражданлык хисен һәм мәдәни тәңгәллекне тәрбияләү аеруча зур әһәмияткә ия. Парламент Рәисе искәрткәнчә, бу төшенчәләр үз дәүләтең һәм җәмгыятеңә битараф булмауны, ил язмышы өчен җаваплылыкны, гражданлык хокукларын һәм бурычларын үтәү зарурилыгын аңлата.

Дәүләт Советы Рәисе сүзләренә караганда, баланы үз иленең чын гражданины, ватанпәрвәр итеп тәрбияләүдә гаилә аерым зур урын алып тора. «Бала яшьтән үк тиешле тәрбия алмаса, үскәч, гражданлык позициясен күрсәтү өчен, үз теләге белән сайлауга бармаячак, дигән фикер белән килешәсездер. Уртак эш өчен җаваплылык хисе тоймый ул чөнки, – дип басым ясап әйтте парламент җитәкчесе. – Нәкъ менә шуңа күрә дә гаиләне, аналар, аталар һәм балаларны сакларга-якларга, аларга ярдәм итәргә кирәк. Бала нәкъ менә гаиләдә гражданлык нигезләренә өйрәнә башлый».

«Республикада балалар һәм яшьләрдә гражданлык хисен һәм мәдәни тәңгәллекне тәрбияләү асылда этник күптөрлелекне, аның төбәк үзенчәлекләрен тануның мөһимлегенә нигезләнә, – дип басым ясап әйтте Фәрит Мөхәммәтшин. – Россиядә гражданлылык төрле милләтләрнең мәдәниятләрен ихтирам итүгә, бер-береңне аңлауга корылырга тиеш. Фәкать шулай гына татулыкка ирешергә мөмкин».

Фәрит Мөхәммәтшин утырышта катнашучыларны бу юнәлештәге эшне көчәйтергә, шулай ук яшьләр белән яңа эш формаларын табарга чакырды.

Илдар Мөхәммәтҗанов

КӨТЕЛГӘН ЯРДӘМ

2024 елның 1 гыйнварыннан авыру бала үстерүче һәм шул ук вакытта эшләүче әти-әниләргә ай саен 10 мең сум акча бирәчәкләр. Элек бу акчаны эшләмәүче ата-аналар гына ала иде. Ә менә эшләүчеләргә 1200 сум түләнде.

Татарстанда яшәүче физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә дәүләттән нинди ярдәм бирелә?

- 248 меңнән артык инвалид торак-коммуналь хезмәтләр өчен субсидия ала. Аларның 15,8 меңе – авыру бала үстерүче гаиләләр. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләнгән сумманың 50 процентын кайтаралар.
- I группа инвалидка һәм аны озатып йөрүчегә хастаханәгә яки ял йортына бару-кайту бушлай. Ташлама тимер юл, автомобиль, су һәм авиация транспортына каралган.
- Тернәкләндерү чаралары бушка бирелә. Моның өчен электрон сертификат тутырырга кирәк. Инвалидларга шәхси тернәкләндерү программасы буенча үзенә тиешле протез, коляска, ишетү аппаратлары бирелә.
- Физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр өчен машина кую бушлай.

Россия Президенты Владимир Путин 18 яшькәчә һәм тумыштан I группа инвалид бала тәрбияләүче әти-әниләргә 10 мең сум пособие түләү турындагы указга кул куйган. Бу акчаны тулы булмаган көн, читтән торып өйдән эшләүчеләр алачак. Тагын шунысы бар: инвалид баланы беркайда да эшләмәүче туганы карый дип рәсмиләштерелә икән, аңа 1200 сум акча түлиләр.

Авыру бала үстерүгә берничи хак куеп булмый, ди үз башларыннан бу хәлләрне кичергән әти-әниләр. «ВТ» журналисты берничә әни белән сөйләште.

– Инвалид бала тәрбияләү җиңел эш түгел. Балаң авыру дигән сүз сине сафтан чыгара. Ул чакта пособие хакында уйламыйсың да икән. Мин үзем шулай булдым. Балама 4 яшь вакытта аны караган өчен 1200 сум акча биргәннәрен белдем. Шунда гына документ тапшырып, рәсмиләштерергә булдым. Инде 7 ел буе шушы акчаны алабыз, – ди Саба районында яшәүче Гүзәл Федорова. – Төрле балада төрле авыру бит. Әйтик, без беркая да дәвалануга бармыйча, өйдә утырсак, балага бирелә торган пенсия акчасы һәм шул пособие җитә. Ә инде ниндидер тернәкләндерү курслары үтсәк, дәвалана башласак, җитми инде. Әле бит баланы ашатасы, киендерәсе дә бар. Кирәк-яраклар да аласы. Дәүләтнең эшләүче әти-әнигә 10 мең сум бирә башлавы бик яхшы. Алданрак та кирәк иде ул. 11 ел авыру бала карыйм, һаман шул 1200 сум акча.

Казанда яшәүче Ландыш Имамиева ДЦПлы бала тәрбияли. Улы – I төркем инвалид.

– Балам авыру булса да, башка сабыйлар кебек, бакчага да йөрде, мәктәптә дә укый. Мин дә эшләдем. Дәүләттән бирелә торган акча турында уйлап та карамадым. Улыма пенсия бирәләр, шуңа риза идем. Узган ел сәламәтлегем буенча эштән китәргә туры килде. Шуннан соң 10 мең сум пособие ала башладым. Гаилә өчен аз акча түгел. Әмма без аны озак ала алмаячакбыз, тиздән улыма 18 яшь тула, – ди Ландыш. – Инвалид бала үстерүчеләргә күбрәк ярдәм булсын иде. Арада II, III группа белән яшәүчеләр бар. Аларның пенсияләре азрак. Ә менә бу акча андыйларга эләкми бит инде. Аларны да онытмаска кирәк.

Сабыйлар арасында шикәр чире, эпилепсия белән интегүчеләр дә бар. Санкцияләр кертелгәч, аларның хәле тагын да авырлашкан. Кызына 2 яшьтә шикәр чире диагнозы куелган Гөлфирә Сафина инде 5 елдан артык өйдә генә утыра.

– Күп кенә кирәк-яракларны үзебез сатып алабыз. Дәүләт биргәнен көтеп утырып булмый. Кызыма шикәрен контрольдә тотар өчен помпа куйдырдык. Болай, ичмасам, бармакларын тишкәләмибез. Безгә кеше ашаганны ашыйсы түгел, бар да башка. Чыгымнар күбрәк. Шуңа күрә дәүләт никадәр генә ярдәм итсә дә, артыгы юк, – ди Гөлфирә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ҺАДИУЛЛИН ДӘРЕСЕ

МИНИСТР ИҢ МӨҺИМ АЛТЫ ТЕМАГА АЧЫКЛЫК КЕРТТЕ

Ел йомгаклары

Өйдә белем алучыларның мәктәпкә кире кайтуы, иминлек мәсьәләсе, телефонсыз дәрес, хезмәт тәрбиясе, туган телләрне укыту һәм укытучыга хөрмәт. Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин ел йомгакларына багышланган матбугат очрашуында әнә шул алты төп темага басым ясады.

tatarstan.ru

Хөрмәт турында

Укытучылар һәм остазлар елындагы хөрмәт киләсе елда да дәвам итәрме? Быел нәрсәләргә игътибар җитеп бетмәгән?

– Укытучы – барыбызның да күз алдында. Сыйныфта – 25 бала. Аларның һәрберсенең әти-әнисе бар. Мәктәптә 40 ел эшләгән укытучыны башлангыч сыйныф укучысы видеога төшерә икән, ул моңа ничек түзәргә тиеш? Әти-әниләр арасында, укытучы балама дөрес карамаган, диючеләр дә бар. Бер балага көлгән, икенчесенә көлмәгән. Укытучыны гаепләп, аңа яла ягудан бернәрсә дә үзгәрмәячәк. Аларны сакларга, матур гамәлләр турында күбрәк сөйләргә кирәк, – диде Илсур Һадиуллин.

Министр әйтүенчә, баланы яратмыйча мәктәптә эшләп булмый. Укытучыларның мәктәптә төпләнеп калмавына да үзебез гаепле. Димәк, балалардан курыккан, һөнәрне дөрес сайламаган яшьләр тәрбияләгәнбез.

Укытучыга хөрмәтне без әле ел ахырында тагын да ныграк сизәчәкбез. Тиздән КФУ базасында «Мәгариф» музее ачылачак. Ул буш тормаячак: студентлар, белем күтәрергә килгән укытучылар, кунаклар да танышa алачак. Укытучыга һәйкәл төзү эше башланган. Без аны «Казан» милли мәдәнияте үзәге янында күрербез. Моннан тыш, укытучыларга багышланган китап та бастырылачак. Аны Укытучылар елының ябылу тантанасында гыйнвар ахырында тәкъдим итмәкчеләр.

– Мөгаллимнәргә карата ихтирам беркайчан да кимемәскә тиеш. Укытучылар елы белән генә чикләнергә ярамый. Укытучыны хөрмәт иткән кешенең киләчәге якты булыр, – ди министр.

Өйдә уку турында

Узган уку елы ахырында өйдә белем алучы укучылар саны 3885 булса, октябрьдә андыйлар 3134кә калган. Димәк, 751 баланы мәктәпкә кайтарганбыз. Министр укытучыларга, мәктәп директорларына укучыларга өйдә белем алуны тәкъдим итмәскә кушты.

– Миннән: «Өйдә белем алу турында фикерегез үзгәрмәдеме?» – дип сорыйлар. Юк, үзгәрмәде. Дөрес, закон өйдә укытуга каршы килми. Авыру, баланың холкына бәйле ниндидер җитди сәбәп булганда аңлыйм әле мин. Әмма тиктомалдан күчүне бер дә хупламыйм. Баланы җәмгыятьтән, аралашудан аеру – зур хата, – ди Илсур Һадиуллин.

Министр әйтүенчә, өйдә уку формасын күбрәк башлангыч сыйныф укучылары сайлый. Югары сыйныфта андыйлар күп түгел. Республикада 11 нче сыйныфны 15 мең укучы тәмамласа, шуның 100е генә өйдә укыган. Гаиләдә укуга күчүдә репетиторларның күбәюе дә бер сәбәп булып тора. Ләкин бу уку сыйфатын арттыруга булышмый. БДИ нәтиҗәләре киресен күрсәтә. Әйтик, өйдә укучы балалар мәктәптәге яшьтәшләренә караганда, математика сынавын – 11, тарихны – 15, географияне 37 баллга түбәнрәк тапшырган.

Чама турында

1 сентябрьдән мәктәпләргә хезмәт тәрбиясе кире кайтты. Хәзер берәү дә баладан, идән юасың, такта сөртәсең киләме, дип сорамый. Закон бар. Моңа кадәр әти-әни гаризасы кирәк иде.

– Туган телләрне өйрәнү өчен әти-әни рөхсәте кирәк. Математика, химияне укыту буенча ризалык сорасаң, алар каршы килергә мөмкин. Юк, минем бала гуманитарий, аңа химия, физика кирәкми, диячәк. Гариза гариза белән, әмма һәрнәрсәнең уйланылган чиге булырга тиеш. Без әти-әниләрнең фикерен хөрмәт итәбез. Әмма соңгы карарны директор хәл итәчәк, – дип аңлатты республиканың баш педагогы.

Телефоннар турында

Билгеле булганча, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» законга үзгәрешләр кертелде. Дәрестә телефон кулланырга ярамый хәзер. Тик әле аңлашылмаган сораулар да бар.

– Телефон кайда саклана: укучының портфелендәме, махсус тартмадамы? Аның өчен кем җавап бирә? Закон кабул ителсә дә, бу мәсьәләгә ачыклык кертелмәгән әле, – диде Илсур Һадиуллин.

Иминлек турында

Республикада 3600 мәгариф оешмасы исәпләнә. Сак хезмәте өчен республикада ел саен 1,5 миллиард сум акча бүлеп бирелә.

– Белем оешмаларын саклаганны барыбыз да белә. Әмма өч метрлы койма корып кына да проблеманы хәл итеп булмый. Балалар җәмгыятьтән ябык булырга тиеш түгел. Безнең бурыч – психологларны да җәлеп итү. Республика мәктәпләрендә 650 шундый белгеч эшли, әмма бу гына җитми. Әти-әниләр балаларының күңел халәтен тоярга, сәламәтлеген кайгыртырга тиеш. Укытучының да ярдәм итүе кирәк. Шул чакта балаларның әхлаксыз гамәлләре турында әйтергә туры килмәячәк, – диде министр.

Туган телләр турында

Республикада бүген укучыларның 63 проценты татар телен өйрәнә. Башкалада андыйлар – 54,4 процент. Журналистлар арасында: «Казанда бу күрсәткеч бик түбән түгелме?» – дип сораучылар да булды.

– Башкалада халык саны да 50гә 50. Шуңа күрә башка милләт укучыларына татар телен мәҗбүри укытырга хакыбыз юк. Һәр халык үз телен сайлап ала. Татар телен исә дәүләт теле буларак өйрәнүче мәктәпләр бар, – диде Илсур Һадиуллин.

Министр, республикада туган телне өйрәтмәгән бер генә мәктәп тә юк, дип ышандырды. Туган тел укытыла торган вариантлар тәкъдим ителеп, контрольдә тотыла. «Федераль программаларга күчү республикада мәгариф өлкәсендә алып барылган сәясәткә комачауламый. Безнең татар теле һәм әдәбияты дәреслекләребез бар. 2022 елда федераль исемлеккә 60 басма кертелде», – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Яңалык

ЗАКОННАРНЫ АҢЛАТАБЫЗ

Дәүләт Советының кырык тугызынчы утырышында кабул ителгән яңа законнар үз көченә керә. Татарстан Рәисе, аерым алганда, «акчалы» законнарны – 2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына республика бюджеты, Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында законны имзалады, агымдагы елга бюджет турында законга, Бюджет кодексына үзгәрешләр кертелде. Моннан тыш яшь буынны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү турында, кайбер социаль ярдәм чараларын җайга салучы законнар үз көченә керде. Аларга тәфсиллерәк тукталып үтәбез.

Чыгымнарның 80 проценттан күбрәге – социаль әһәмиятле

Киләсе елның 1 гыйнварыннан «2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 116 нчы Закон үз көченә керә.

2024 елга төзелгән бюджет, алдагы еллардагы кебек үк, социаль юнәлешле һәм билгеле бер программалар кысасына кертелгән. Аерым алганда, бюджет акчасының 80 проценттан артыграгы беренче чиратта кирәкле, социаль әһәмиятле чыгымнарга юллана.

Бюджетта чыгымнарның 90 проценттан күбрәге дәүләт программалары (Татарстанның 32 дәүләт программасы гамәлгә ашырылачак) буенча бүленгән.

Шулай ук анда бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең аерым категорияләренә хезмәт хакын арттыру күздә тотылган, халык алдындагы бурычларны үтәү чыгымнарын индексацияләү исәпкә алынган, аерым категорияләргә, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучыларга, аларның гаиләләре әгъзаларына һәм балалы гаиләләргә ярдәм чаралары өчен акча каралган.

Шулай итеп, Татарстан бюджеты түбәндәге күрсәткечләр белән расланган:

2024 елда

керем – **399** миллиард **599** миллион **130** мең **100** сум,
чыгым – **399** миллиард **599** миллион **130** мең **100** сум;

2025 елда

керем – **403** миллиард **592** миллион **206** мең **900** сум,
чыгым – **416** миллиард **90** миллион **167** мең **200** сум.
Дефицит – **12** миллиард **497** миллион **960** мең **300** сум;

2026 елда

керем – **427** миллиард **404** миллион **227** мең **900** сум,
чыгым – **446** миллиард **275** миллион **971** мең **200** сум.
Дефицит **18** миллиард **871** миллион **743** мең **300** сум күләмендә тәшкил итәчәк.

Медицина ярдәменә чыгымнар арта

2024 елның 1 гыйнварыннан «2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» 117 нче Закон үз көченә керә.

Бюджеттагы саннар социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә исәпләп чыгарылган. Керемнәрнең төп өлешен Федераль мәҗбүри медицина иминияте фондыннан Татарстандагы медицина иминияте оешмаларына субвенцияләр тәшкил итә. ОМС фонды бюджеты чыгымнарының иң зур өлешен «Сәламәтлек саклау» бүлеге буенча чыгымнар (99,4%) тәшкил итә.

Законда түбәндәге күрсәткечләр расланган:

2024 елда

керем – **79** миллиард **605** миллион **662** мең сум,
чыгымнар – **79** миллиард **605** миллион **662** мең сум;

2025 елда

керем – **84** миллиард **567** миллион **409,6** мең сум,
чыгымнар – **84** миллиард **567** миллион **409,6** мең сум;

2026 елда

керемнәр – **89** миллиард **791** миллион **229,2** мең сум,
чыгымнар **89** миллиард **791** миллион **229,2** мең сум күләмендә тәшкил итәчәк.

Бу чорларга бюджет дефициты планлаштырылмый.

Социаль ярдәм

4 декабрьдә «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 118 нче закон үз көченә керде.

Законда, геосәяси, икътисадый вазгыять начараю очрагында, республика бюджеты дефицитының һәм дәүләт бурычларының чик күләмен икътисадка, халыкка ярдәм итүгә җибәрелгән акча күләменә арттыру мөмкинлеге билгеләнгән.

Бюджет, салым һәм финанс комитеты рәисе Леонид ЯКУНИН:

– 2024 елга бюджет турында законга кушымта итеп дәүләт гарантияләре һәм дәүләтнең эчке кредитлары программаларын рәсмиләштерү таләбе буенча, Бюджет кодексы нигезләмәләренең гамәлдә булуы туктатып торыла. Моннан тыш бюджет дефициты, дәүләт яки муниципаль бурычның чик күләмен икътисад тармакларын торгызу чаралары на, оборона һәм ил иминлегенә, халыкның аерым категорияләренә социаль ярдәмгә юнәлдерелгән акча күләменә арттыру рөхсәт ителә.

Сату-алу килешүен төзү вакыты кими

15 декабрьдә «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 120 нче закон үз көченә керде.

Закон урманнарны янгыннардан саклауны көчәйтүгә һәм ашыгыч төстә федераль мөмкинлекләрне җәлеп итүнең нәтиҗәсен яхшыртуга юнәлдерелгән.

Документта урман мәнсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Рәисенең вәкаләтләре киңәйтелгән. Аерым алганда, Урман хуҗалыгы федераль агентлыгының ашыгыч чаралар күрү турындагы карарын Татарстан Рәисе белән килештерергә тиешлеге билгеләнгән.

Моннан тыш республика Урман хуҗалыгы министрлыгының вәкаләтләре тәгаенләнгән. Хәзер министрлык Татарстан урманнарын янгыннан саклау планын эшләүгә, шулай ук урман хуҗалыклары янгыннан саклау планын эшләп раслауга җаваплы.

Законда, халыкка уңайлы булсын өчен, урманнардагы агачларны, аукцион үткәрмичә генә, үзләренең ихтыяҗына сату-алу килешүен төзү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын 15 көннән 10 эш көненә калдыру күздә тотылган.

Компенсация түләү тәртибе гадиләштерелә

1 гыйнвардан «Татарстан Республикасында яшәүчеләрне адресны социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 8.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 125 нче закон гамәлгә керә. Анда яман шеш һәм бөер авыруларыннан интегүчеләргә дәвалану урынына барып кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибе гадиләштерелә.

Моңа кадәр гаиләдә җан башына уртача керем ике яшәү минимумыннан кимрәк булганда гына юл чыгымнарын каплаганнар. Законда мохтаҗлык буенча таләп юкка чыгарылган. Хәзер гаилә керемена бәйсез рәвештә бу чарадан файдаланырга мөмкин.

Ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү

11 декабрьдә «Татарстан Республикасы гражданнарын ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү турында» 123 нче Закон үз көченә керде. Ватанпәрвәрлекне тәрбияләүгә бердәй караш булдыруны, бу өлкәдәге мөнәсәбәтләрне җайга салуны күздә тоткан закон бу.

Документта ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү өлкәсендә республика дәүләт сәясәтенең бурычлары билгеләнгән, бу өлкәдә Татарстан дәүләт хакимияте органнары арасындагы вәкаләтләр бүленгән.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИН:

– Ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү мәсьәләсе кайчандагыга караганда да кискенләште. Барлык профильле министрлыклар һәм башкарма хакимият органнары эшенә кагыла бу. Яшь буынны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү, кыйммәтләрне тапшыру – чиктән тыш мөһим бурыч.

Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат ЗАРИПОВ:

– Законның аерым статьялары кешеләребезнең һәм коммерциясез оешмаларның яшь буынны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләвенә багышланган. Анда җирле үзидарә органнарының мондый эшчәнлектә катнашуга һәм бу өлкәдә муниципаль программаларны раслауга хокукы билгеләнгән.

Нотариус бушлай эшли

1 гыйнвардан «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 119 нчы Закон үз көченә керә.

Анда нотариусларның бушлай юридик ярдәм күрсәтүдә катнашуы җайга салынган. Аерым алганда, алар, судларда адвокатларның (бушлай юридик ярдәм программасында катнашучы) тегге яки бу кеше исеменнән эш итүе өчен, ышанычнамәне түләүсез рәсмиләштерәчәк.

Биредә сүз республика законнары нигезендә бушлай юридик ярдәм алуга хокуклы кешеләр турында бара. Аерым алганда, болар – аз керемлеләр, I һәм II төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, махсус хәрби операциядә катнашучылар, инвалид балалар, ятимнәр (тулы исемлеге «Татарстан Республикасында гражданнарга бушлай юридик ярдәм күрсәтү турында» 73 нче законда билгеләнгән).

Әйтик, күчемсез милек белән алыш-биреш, социаль наем килешүе буенча торакка хокукны тану, территориясендә йорт булганда җир кишәрлегенә хокукны саклау очракларында юридик ярдәмгә түләнелми.

Дәүләт хезмәтләре аша юллана

22 декабрьдә «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 124 нче Закон үз көченә керә.

Анда халыкның Дәүләт хезмәтләре порталы аша мөрәҗәгатьләр юллау һәм җавапларны шәхси кабинетка юллау мөмкинлеге каралган. Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, башка оешмалар бу эшне 2025 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча оештырырга тиеш.

КОТЛЫЙБЫЗ!

«ТЭКОРЕСУРС» махсуслаштырылган торак төзүче оешма җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Ковалев** Руслан Николаевичка, Россия Федерациясе Герое, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Хәрби һәм Хезмәт Даны орденнары тулы кавалерларының Татарстан Республикасы иҗтимагый хәйрия оешмасы рәисе **Хәйруллин** Газинур Гарифҗан улына, «Казан энергетика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорының административ-хуҗалык часте буенча урынбасары **Вәлиуллин** Азат Миңнулла улына, «Спас күптармаклы технологияләр техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе директорының укыту-производство эше буенча урынбасары **Герасимова** Екатерина Александровнага, «Казан технология һәм дизайн көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе лабораторияләре мөдире **Дмитриева** Татьяна Александровнага, «Н.В. Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең производствода эшкә өйрәтү мастеры **Җиһангәрәев** Рудик Радик улына, «Лениногорск музыка-сәнгать педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең сәнгать-графика дисциплиналары укытучысы **Курганская** Елена Николаевнага, «ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү учреждениесенең инклюзив белем бирү институты директоры **Мелина** Елена Валериевнага, «Казан сәүдә-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Таҗиева** Мәрьям Фәһим кызына, «Лениногорск политехник көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең производствода эшкә өйрәтү мастеры **Таҗиева** Рәмзия Әбзәт кызына, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Минзәлә муниципаль районындагы сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен «Умырзая» тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең социаль эш буенча белгече **Тимерханова** Оксана Владимировнага, «Казан сәүдә-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Царева** Мария Арнольдовнага, «П.В. Дементьев исемендәге Казан авиация-техник көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең махсуслаштырылган компетенцияләр үзәге җитәкчесе **Шубина** Мария Евгеньевнага, «Халыкара сервис көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең махсус дисциплиналар укытучысы **Биккинина** Эльмира Альмир кызына, «Казан сәүдә-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Блинова** Алена Дмитриевнага, «В.Д. Поташов исемендәге техника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Будкина** Татьяна Николаевнага, «Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең шәфкать туташлары эшләү укытучысы **Гарипова** Альбина Шәйдулла кызына, «Чаллы педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең информатика укытучысы **Голубева** Яна Станиславовнага, «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган өстәмә белем бирү оешмасының өстәмә белем бирү педагогы **Латыйпов** Рөстәм Динфир улына, «Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Мерзлов** Александр Геннадьевичка, «Әлмәт политехника техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең махсус төзелеш дисциплиналары укытучысы **Михайлова** Елена Михайловнага, «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең директорының уку-укыту эше буенча урынбасары **Тимофеева** Оксана Сергеевнага, **«Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе коллективына Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

Мәдәният

Моң берләштерә

«Кызый, ничәнче тапкыр киләбез инде без монда? Бишме, алтымы?» Татар дәүләт филармониясенең фойесында ике матур гына әбекәй сөйләшеп торуына колак салдым. «Агыйдел»не шулай яратасызмыни?» – дип сорадым, түзмичә...


Руслан Усманов

Җырлап җавап бирде алар. «Туган якка кайтып, Агыйдел буенда җәяү йөргән кебек булабыз», – диделәр. Актанышның «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбленең Казандагы концертына үземнең дә өченче тапкыр килүем искә төште. Үз теләгем белән, билгеле.

Шулай итеп, быел да Актаныш төбәгеннән чыккан талантлар, якташларын да, якташ булмаганнарны да бер зур залга җыеп, өч сәгатьлек тамаша күрсәтте. Алар ел саен концертларын билгеле бер темага багышлый иде. Бу юлы ул, Татарстанда төгәлләнеп килүче Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын исәпкә алып, милләтара татулык, дуслык һәм бердәмлеккә багышланды.

Дөресен генә әйткәндә, соңгы берничә ел дәвамында мондый рухтагы тамаша-концертларны шактый күрергә туры килде. Төрле милләт вәкилләренең милли киемнәре, җыр вә биюләре яхшы таныш кебек тоела иде. «Агыйдел» исә кайбер милләтләрнең, аеруча читтә яшәүче татарларның биюләренә гашыйк итте. Бу аларның һәр хәрәкәткә игътибарлы булуына бәйледер. Әйтик, ансамбльгә мари халык биюен Мари Элдан чакырылган остаз куеп биргән. Шуңа аның рухы бөтенләй башка иде. Бер яктан, биюче егетләрнең бертуктаусыз тыпырдаудан аяклары авыртмаса ярар иде, дип борчылсак (янымдагы апалар белән), икенче яктан, тынгысыз ритм белән нәзакәтлелекнең бер биюдә «яши» алуы сокландырды.

Билгеле, бу кичтә мәртәбәле кунаклардан «Агыйдел»гә карата күп мактау сүзләре дә ишетелде. Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, беренче чиратта, зур шәхесләр бүләк иткән «Актанышның уңдырышлы туфрагы»н мактады.

– Ел ахырына якынлашканда «Агыйдел» ансамбленең Казанда концерт куюы матур бер традициягә әйләнде. Һәм бу, чын мәгънәсендә, бик әһәмиятле чара, – диде ул. – Актаныш – күпмилләтле район. Әлеге районның уңдырышлы туфрагы безгә бик күп бөек шәхесләр бүләк итте. Актаныш халкының татар теленә, татар әдәбиятына, татар җыр сәнгатенә керткән өлеше гаять зур. Без моның белән чиксез горурланабыз!

Район башлыгы Ленар Зарипов, ансамбльне ярату, «Агыйделкәебез» дип атады.

– Зал тутырып килгәнегез өчен мең рәхмәт, кадерле тамашачылар! Әле кайчан гына очрашкан кебек идек... – диде ул, Актаныш халкы исеменнән кайнар сәламнәр җиткереп.

Актаныш якташлар җәмгыяте рәисе Вәсим Вахитов тәңкәнең ике яклы булуын искәртте.

– «Агыйдел» – легендар ансамбль. Кая гына барып, нинди генә чараларда чыгыш ясамады алар. Чын мәгънәсендә данлыклы дәүләт ансамбле. Ләкин бу матурлыкның икенче ягы да бар. Ансамбль яшәсен өчен, аны финансларга кирәк. Сез костюмнарны күрегез! Затлы, зәвыклы... Шөкер, барысына да республикабыз ярдәм итә, – диде ул. – Актаныш артта кала алмый, чөнки ул – Татарстанга Беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улын биргән як. Без начар җырлый алмыйбыз, чөнки легендар шәхес, «җыр патшабикәсе» Әлфия апа Авзалова да – безнеке.

Татарстан чигендә яшәп һәм эшләп тә, дәүләт ансамбле исемен күтәрергә, ел да эчтәлекле программа уйларга, Вәсим әфәнде әйтмешли, затлы-зәвыклы костюмнар тектерергә, чит төбәкләрдәге чараларны калдырмаска... Уйлап карасаң, кечкенә генә Актаныштa зур эшләр майтарып ята «Агыйдел»челәр. Бу юлы әнә Казан халкы алдындагы имтихан-концертларын якташ җырчыларыннан башка да куеп чыктылар. Җырчыларны теләсә кайсы вакытта күреп һәм тыңлап була ла ул, шоуга корылган чорда эчтәлекле һәм затлы концертлар тансыграк бит.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«Татар-информ»

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ИЛСӨЯ

Концерттан соң

Татар эстрадасын яңа дәрәҗәгә күтәргән грандиоз тамаша, берсеннән-берсе затлы костюмнар, чиксез тамашачы мәхәббәте... Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинованың концертын берничә сүз белән тасвирларга кушсалар, әнә шуларны әйтеп булыр иде. 21 ел буе сәхнә тоткан җырчы быел тамашачыга «#едриткудрит» дип исемләнгән яңа программасын тәкъдим итте. Илсөя Бәдретдинованың Казандагы 12 көнлек традицион концертын безгә дә барып күрергә насыйп булды.

Насыйп булды диюем юкка түгел. Илсөя Бәдретдинова концертларына көнендә генә эләгәм, димә. Әйтик, шул ук Казан концертларына билетлар ике ай алдан ук сатылып беткән иде. Ел саен шундый хәл. Җырчының тамашачы күңелендә нинди урын алып торуын әнә шуннан да чамаларга мөмкин.

...«Уникс»ның бер меңнән артык кеше сыйдырышлы концертлар залында алма төшәрлек тә урын юк. Сәхнә бизәлеше, махсус эффектлар, көчле энергетика... Илсөя Бәдретдинованың һәр чыгышы шулар белән үрелеп барды. Залдагы тамашачы һәр җырның сүзләрен белә. Бу аңлашыла да. Аларның һәркайсында һәркайсыбызга таныш халәт, тарих, хисләр урын алган. Җырчыга кушылып җырлап утыручылар да, залдагы энергетикага каршы тора алмыйча, утырган җиреннән торып басып биючеләр дә шактый булды. Илсөя – Илсөя инде! Аның концертларында башкача була да алмый!

Моннан егерме ел элек үз юлы, үз стиле белән өермә кебек килеп кергән үзенчәлекле җырчы бүген дә үз юлы белән атлавын дәвам итә! Беркемне дә кабатламый, киресенчә, һәр концерты моңарчы татар эстрадасында күренмәгән берәр яңа алым белән истә кала. Быел, мәсәлән, сәхнә биеклеге белән чикләнеп калмыйча, җырлый-җырлый түшәмгә кадәр үк күтәрелде ул.

Шундый катлаулы номерны «ых» та итми башкарып чыгуына бер гаҗәпләнсәк, шул мизгелдә бер секунд эчендә өстендәге киемен алыштырырга өлгерүенә икеләтә таң калдык. Гомумән, җыр саен тиз арада күлмәк алыштыру – Илсөянең иң төп фишкаларының берсе. Кай арада өлгерә ул аңа?! Быелгы концертта 12 күлмәк алмаштырганын төгәл санадым, аннары инде исәбен югалттым. Җырчының һәр күлмәге затлы, кабатланмас. Илсөя үзе генә түгел, төркемдәге егет-кызларның өлгерлегенә дә күзләр иярми. Әле бит алар арасында тамашачыны ялыктырырлык пауза әсәре дә юк.

Халыклар, милләтләр дуслыгы турында күп ишетергә туры килә. Моның тормышта ничегрәк икәнен күрергә теләүчеләр һич икеләнмичә Илсөя Бәдретдинова концертына бара ала. Бүген аның төркемендә 5 милләт, 3 дин вәкиле эшли. Татар, рус, башкорт, керәшен, якут милләтеннән булган кыз һәм егетләрне тамашачы исемләп белә. Илсөя исә аларның һәркайсы турында, горурланып, «минекеләр» ди.

– Меңләгән талантлар арасыннан берәмтекләп җыеп алган алтын бөртекләрем алар минем. Алар музыкант, җырчы, биюче генә түгел. Алар – бөтен яктан да уникаль, универсаль шәхесләр. Безнең сәхнә артына керсәгез, шундый күңелле. Берсе почмакта чукына, берсе урындыкка утырып бисмилласын укый, берсе идәнгә ятып нәрсәдер тыңлый. Үлеп яратам шуларны. Һәрберсе белән озын-озак еллар эшләргә насыйп булсын, – ди Илсөя үзе.

Илсөя Бәдретдинова тамашачысына да атлаган саен рәхмәт әйтә. Әйтерлек тә бит! Иҗат кешесе өчен ике дистә ел буе янәшәдән атлап барган тугры тамашачысы булудан да зур бәхет юктыр ул. Үзенә булган бу ихтирамны сәхнәдә утырган һәр тамашачы сизгәндер, мөгаен. Концертның башыннан ахырынача залда җылы, дустанә, рәхәт мохит урнашты. Күп кенә концертларда күзәтелә торган «менә мин – кәттә артист, син – тамашачы» дигән ташка язылмаган, әмма әллә кайдан сизелеп торган бүленеш тә юк иредә. Озак еллар дәвамында бергә булган якын кешеләрнең бер күрешеп, хатирәләрне барлап, җырлашып утыруын хәтерләткән рәхәт кич. Концерт барышында тамашачы арасында сәхнәгә үк менеп биюче, җырлаучылар да булды хәтта.

Казанның 9 нчы шәһәр стоматология клиникасында шәфкать туташы булып эшләүче Рамилә Гафиятова яраткан җырчысының концертына инде унөченче ел рәттән килә икән.

– Быел Илсөя концертында күңел халәтен күбрәк күрсәтә. Җырларында, сөйләгән һәр сүзендә әти-әнисен, туганнарын, авылын, авылдашларын сагынып яшәве сизелә. Татар халык киеменнән чыгышы аеруча ошады, – ди Рамилә Гафиятова.

Концертта, дөрестән дә, бер туктап уйланырлык мизгелләр дә шактый. Илсөянең тәмләп балачак хатирәләрен сөйләгәнен елмаеп тыңлап утырган җирдән, бермәлгә күңелгә моңсу бер хис кереп оялый да гомернең бер мизгел генә икәнен, әти-әнине, якыннарыңны исән чакта кадерләргә кирәклегенә тагын бер кат инанасың. Бу урында залда бик сирәкләр генә күз яшен тыеп кала алды.

Әмма озаклап моңсуланып утырырмын димә! Илсөя тамашачы халәтен бик оста тоемлый. Фәлсәфә артыннан шундук бер кызык сүзен әйтеп көлдереп, «уятып» та җибәрә! «Мәтрүшкә»ләрне җырлап бетергәч, алгы рәттә утырган бер әбигә карап: «Менә бу апа концерт башланганнан бирле ике тапкыр гына елмайды. Календарь бүләк итик әле шуңа, рәхәт булып китсен», – дип шаяртып та алды.

Ак яулыклы бу апа Казанның «Жилплощадка»сында яшәүче 76 яшьлек Әклимә Мөхәммәтгалиева булып чыкты. Яраткан җырчысының концертын карарга улы, килене, оныгы, кодагые белән килгән ул.

– Илсөя бигрәк җор телле инде, һәрвакыттагыча шаярта. Ике тапкыр гына түгел, кәнсирт буе елмаеп утырдым. «Мәтрүшкәләр»не тыңлаганда елап та алдым. Моңа кадәр концертларын телевизордан гына карый идем. Залдан карау бөтенләй башка икән, – диделәр.

Билетлар бар, әмма алары да санаулы гына. Илсөянең декабрь концертына эләгә алмаучыларның күбесе анда майда бару җаен күптән кайгыртып куйган инде. Яраткан җырчылары яз башында тагын унбер көн Казан сәхнәсен гөрләтәчәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Ватан хакына

АНА ЙӨРӘГЕ

Кайбыч районының Мәлки авылында яшәүче ирле-хатынлы Таракановлар, 4500 чакрым юл узып, хәрби операциягә үзләренең ике машиналарын илтеп тапшырган. Читтә калырга намус та, йөрәк тә, күңел дә кушмый, тик барыннан да бигрәк аларны бала хакы йөртә. Ерак юл узып, алгы сызыкка кадәр барып җиткән ананың үзе белән сөйләштек.

– Аңа кадәр ирем Василий хәрби операция зонасына үзе генә барып кайтты. Сугыш кырындагы егетләргә ярдәм булыр дип, үзебезнең җиңел машинаны илтеп бирде, – дип башлады сүзен Хәлимә Тараканова. – Тик аның белән пычрак ерып йөрү авыр бит, ватылып та китте. Бер сөйләшүебез вакытында улыбыз Александр техника кирәклеген әйтте. Алар, үзләре яшәгән урыннан авыл кибетенә барып, ризыклар сатып ала иде. Ышанычлы машина шуның өчен дә, запас частьлар, башка әйберләр ташыр өчен дә кирәк иде. Улымның шушы сүзләре күңелдәге тынычлыкны тагын да ныграк бетерде. «Табыныбыз тулы ризык булганда, улыбыз ач ятсынмы инде?» – дип уйлаштык та үзебезнең «ГАЗель» машинасын илтеп бирергә булдык. Ирем аның руленә утырды, мин үз машинамда юлга кузгалдык. Үзем барасын белгәч, борчылып, ике көн йокламадым, чөнки мин бит машина белән Казан эчендә дә йөргән кеше түгел. Ә монда дүрт меңнән артык чакрым юл узып кайтырга кирәк. Тик бала хакына барысына да түзәсең икән ул.

Сентябрь ае була ул. Хәлимә апаның үзенең дә сәламәтлеге белән проблемалары бар. Аягы авыртканлыктан, юлга үзе белән система, даруларын да ала. Тик сер бирми. Иң мөһиме – улы янына исән-имин барып җитсеннәр дә «ГАЗель»не кулларына тапшыра алсыннар. Күп итеп камыр ризыклары пешереп ала, барысына да җитәрлек итеп, сый-нигъмәтләрен, яшелчәсен, тәм-томнарын тутыра. Юлга ике көн вакыт китә. Төнлә барып җитәләр дә икенче көннең кичендә кабаттан юлга кузгалалар.

– Аннан кайткач, ике атна тынычлана алмадым. Безне күрүгә, әзмәвердәй ир-атлар да елап җибәрде. Аларның һәркайсының сагышлы, моңсу карашы, күз яше түгәре әле дә булса уемнан чыкканы юк, – дип елый олы йөрәкле ана. – Кызганыч, кайбер ризыклар юлда бозылган иде. Тик калганнарын егетләр рәхмәт әйтеп, сөенеп ашады. Күңелемә ничек кенә авыр булса да, улым янында көчле булырга тырыштым. Шуңа күрә уйнап-шаярып сөйләшергә тырыштык. Җанымдагы давылны басарга юлга алган тынычландыра торган дарулар да ярдәм иткәндер. Аннан соң ирем дә: «Борчылма, елама, барысы да яхшы булачак», – дип, гел әйтә килде.

Таракановлар үзләре белән улларының дүрт аяклы якын дустын – Квенсия кушаматлы этен дә ала. Армиядә хезмәт иткәндә хөрмәт казанган егеткә командирының бүләге була ул.

– Шалтыратканда башта безнең, аннан соң этенең хәлен бөртекләп сораштыра улыбыз. Шуңа күрә үзебез белән аны да алып барырга булдык. Аларның очрашу мизгелләрен күрсәгез иде сез! Хәтта этнең күзләре яшьләнде, – ди ул.

Армиядә Ижевск шәһәрендә хезмәт итә Александр. Кайтыр вакыты җиткәч, контракт белән хезмәт итәргә кала. Ел ярым хезмәт иткәч, узган елның июлендә аны Чита шәһәрендәге хәрби частька җибәрәләр. Бер-ике атнадан, өч айга дип, Украинага командировкага юллыйлар да үз частена кире кайтармыйлар.

– Контракт төзегән вакытта дөньялар тыныч иде бит әле. Бу хәлләр булыр дип кем уйлаган? Украинага кузгалыр алдыннан фотосын гына төшереп җибәрде, – диде дә тынып калды ана. Аннан соң көч туплап: – Бик кыен да соң, тик бирешергә дә ярамый... Улыбыз кешегә ышыкланып кала торган кеше түгел. Һәрвакыт алдан йөрде, кыю, тәвәккәл, максатчан егет. Яу кырында да сынатмыйдыр дип уйлыйм.

Минем шалтыратуым да Хәлимә апаның тынгысыз, эчендә ут уйнаган вакытына туры килде. Улы ун көннәр элек «беренче линия»гә кереп киткән икән. Ана улының яу кырыннан чыкканын көннәрне түгел, минутларны санап көтә:

– Февральдә бик көчле бәрелешләрдә катнаштылар балалар. Ул вакытта бер ай дәвамында элемтәгә бөтенләй чыга алмадылар. Ничек өзгәләнүемне үзем генә беләм. Кая гына барсам да, ни генә эшләсәм дә, уемда балам гына булды. Шушы бер айда 15 килога ябыктым. Ул әйтеп калдырган телефон номерларына да шалтыратып тордым, ләкин ул кешеләр дә: «Ходайдан сорагыз, берни дә белмибез», – диюдән ары узмады. Бер айдан соң хәбәре килде. Нибары ике сүз язган иде улым. Бик өзелеп көткән ике сүз иде ул: «Мин исән!»

Тынгысыз ана белән ата тиздән кабат юлга кузгалмакчы булалар.

– «Яңа елга кадәр тагын килербез», – дип, егетләргә вәгъдә итеп кайттык бит. Аларга җылы киемнәр, одеял, оекбаш, җылы эчке киемнәр кирәк. Шул бурычыбызны үтисебез бар. Анда безне көтәләр...

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13596 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 368

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+